БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«20» 11 2024 ел № 272

2025 елда Балтач муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүне һәм эш белән тәэмин ителүен оештыру турында

Балаларны яклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру, 2025 елда балаларның һәм яшьләрнең Балтач муниципаль районы территориясендә ялын оештыру өчен кирәкле шартлар тудыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 05 мартындагы «Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 158 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 29 апрелендәге «Балаларның һәм яшьләрнең ялын һәм сәламәтләндерүен оештыру турында» 346 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының 2022 елның 16 маендагы «Балаларның һәм яшьләрнең ялын һәм сәламәтләндерүен оештыру турында» 2020 елның 29 апрелендәге 346 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 446 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының 2023 елның 8 сентябрендәге «2024-2026 елларга Татарстан Республикасында балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында» 1110 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Расларга:

- «2025 елга Балтач муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен һәм эш белән тәэмин ителүен оештыру» программасы (1 нче кушымта).

- Балтач муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүне һәм эш белән тәэмин ителүен оештыру турында Нигезләмә (2 нче кушымта).

- Балтач муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен һәм эш белән тәэмин ителүен оештыру буенча ведомствоара комиссия турында Нигезләмә (3 нче кушымта).

- Балтач муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен һәм эш белән тәэмин ителүен оештыру буенча ведомствоара комиссия составы (4 нче кушымта).

- Балтач муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ял һәм сәламәтләндерү оешмаларын әзерләп бетерү һәм аларны комплекслы тикшерү буенча эшче төркем составы (5 нче кушымта).

2. Балаларның һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен һәм мәшгульлеген оештыру өлкәсендә эшчәнлек алып баручы төрле милек рәвешендәге предприятиеләргә, оешмаларга, учреждениеләргә тәкъдим итәргә:

- балаларның һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүне һәм мәшгульлеген оештыру системасын саклап калу, сәламәтләндерү оешмаларын, төрле типтагы һәм милек рәвешендәге лагерьларны үстерү буенча чаралар күрергә;

тәэмин итәргә:

- авыр тормыш хәлендә калган балаларның, ятим балаларның, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның; инвалид балаларның, сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән, ягъни физик һәм (яисә) психик үсешләрендә кимчелекләре булган балаларның, кораллы һәм милләтара конфликтлар, экологик һәм техноген катастрофалар, табигый бәла-казалар корбаны булган балаларның; гаиләләрдәге балаларның ялын һәм сәламәтлеген ныгытуны оештыру; качаклар һәм мәҗбүри күченүчеләр гаиләсендәге балалар, экстремаль шартларда калган балалар; көчләү корбаннары булган балалар, тәртибе девиант (иҗтимагый яктан куркыныч) булган, махсус тәрбия, белем алу шартларына мохтаҗ һәм махсус педагогик якын килүне таләп итүче белем алучылар өчен мәгариф оешмаларындагы балалар, килеп туган хәлләр нәтиҗәсендә тормыш эшчәнлеге объектив рәвештә бозылган һәм әлеге хәлләрне мөстәкыйль рәвештә яисә гаилә ярдәме белән җиңә алмаган балалар; Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2004 елның 17 декабрендәге«Татарстан Республикасында халыкның аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 542 номерлы карары белән билгеләнгән тәртиптә балага ай саен бирелә торган пособие алучылар булып торучы гаиләләрдә җан башына уртача кереме яшәү минимумы күләменнән түбәнрәк булган гаиләләрдәге балалар «Татарстан Республикасында социаль реабилитациягә мохтаҗ балигъ булмаганнар, махсуслаштырылган оешмаларда тәрбияләнүчеләр, социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләрдәге

балалар өчен;

- иҗади сәләтле һәм социаль актив балаларның, балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре активы әгъзаларының, 7 яшьтән 17 яшькә кадәрге балаларның ялын һәм сәламәтләндерүне оештыру;

- палатка тибындагы лагерьда профильле сменада балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру;

- балалар һәм яшьләр өчен көндезге ял лагерында (мәктәп яны лагерында) сменалар оештыру;

- балаларның һәм яшьләрнең хезмәт һәм ял лагерьларын оештыру;

- социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләрдәге иң күп санда балаларга оештырылган ял өчен шартларны;

- ял оешмаларында һәм оештырылган ял урыннарында балаларның иминлеген һәм сәламәтлеген, хокук тәртибен, санитар-экологик һәм янгынга каршы куркынычсызлыкны тәэмин итүгә юнәлдерелгән санитар-эпидемиологик чаралар комплексын эшләү һәм уздыру;

- аларның янгын куркынычсызлыгы таләпләренә, санитария кагыйдәләренә туры килүен, хезмәткәрләрнең хезмәтен саклау шартларын һәм торышын, ял итүчеләрнең иминлеген тикшерү максатыннан, балаларның һәм яшьләрнең ял һәм сәламәтләндерү оешмаларын ачу алдыннан оештыруны һәм аларны комплекслы тикшерүне;

- балаларның һәм яшьләрнең ял һәм сәламәтләндерү оешмаларының санитар кагыйдәләренә һәм нормаларына туры килү шарты белән, шулай ук Кулланучылар хокукларын яклау һәм кешенең уңай тормышы өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Биектау, Арча, Әтнә, Балтач районнарында территориаль бүлегенең санитар - эпидемиологик бәяләмәләре, Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсенең күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик эш идарәсе Кукмара һәм Балтач муниципаль районнары буенча күзәтчелек эшчәнлеге районара бүлегенең тиешле рөхсәте булган очракта, балаларның һәм яшьләрнең ял һәм сәламәтләндерү оешмаларын ачу алдыннан оештыруны;

- балаларның ял оешмалары тарафыннан санитар кагыйдәләрне үтәүне һәм лаборатор-инструменталь тикшеренүләр үткәрүгә билгеләнгән тәртиптә аккредитацияләнгән лабораторияләр белән килешүләр төзү юлы белән санитария-эпидемияләргә каршы (профилактик) чаралар үткәрүне;

- ял оешмаларына кабул ителгән балалар турында, профилактик прививкаларның милли календаре нигезендә йогышлы авыруларга каршы прививкалар ясатуның торышы турында, яшәү, тәрбияләнү, уку урыны

буенча йогышлы авырулар белән элемтәләрнең булмавы турында, туберкулез диагностикасы, флюорография тикшерүе (15 яшьтән яшүсмерләргә) нәтиҗәләре турында, гельминтозларга һәм эчәк протозоаларына тикшерү, йогышлы чирләрне, шул исәптән педикулезга тикшерүләр турында медицина документларында белешмәләр булуны;

- урман-техник чаралар үткәрү (агачларның, куакларның түбән үсүче һәм коры ботакларын кисү, яшь үсенте кисү, үлән чабу, балаларның ял оешмалары территориясеннән коры ауган агачларны һәм чүп-чарны чыгару), дератизация һәм талпанга каршы эшкәртелгән урыннарга кадәр лагерь тирәли 500 метр радиуста коры ауган агач һәм чүп-чар чыгару һәм бөтен ялны оештыру кампанисе дәвамында, кирәк булган саен;

- барлык корылмаларны, шул исәптән файдаланылмый торганнарын да, ачык территорияне, 500 метр радиуста балаларның ял оешмалары тирәсендәге киртәләрне 35 - 40 көн алдан һәм ачу алдыннан җиде көн алдан һәм аларны консервацияләү алдыннан дератизацион эшкәртү, шулай ук сменалар арасында һәр дератизацион эшкәртүдән соң 30 көн узгач нәтиҗәлелекне контрольдә тотуны;

- ачылу алдыннан 20-25 көн кала, балаларның ял оешмалары территориясен һәм аның әйләнәсендәге 50 метрлы зонаны, шулай ук талпан йогышлы энцефалиты буенча эндемик территорияләрдә урнашкан балаларның стационар ял оешмаларында сменалар арасында талпанга каршы эшкәртүне, талпанга каршы һәр эшкәртүдән соң өч-биш көннән һәм 15-20 көннән соң ике тапкыр нәтиҗәлелеккә контроль үткәрүне;

- балаларның коллектив ялын оештыручылар тарафыннан Татарстан Республикасы территориясенә аеруча куркыныч инфекцияләр кертүне, төркемле йогышлы авырулар килеп чыгуны кисәтү максатларында, җибәрүгә кадәр кимендә өч тәүлек алдан оештырылган балалар коллективларын республика чикләреннән җибәрүнең планлаштырган вакыты турында Кулланучылар хокукларын яклау һәм кешенең уңай тормышы өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Биектау, Арча, Әтнә, Балтач районнарында территориаль бүлегенә хәбәр итүне;

- Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 331 статьясында каралган педагогик эшчәнлек белән шөгыльләнүгә каршылыклар булу (булмау) предметына ялны оештыруда эшкә урнашучы (эшләүче) затларны алдан тикшерүләр оештырырга;

- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Балалар төркемен автобуслар белән оешкан төстә йөртү кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 23 сентябрендәге 1527 номерлы карары белән расланган Балалар төркемен

автобусларда йөртүне оештыру кагыйдәләре нигезендә балаларны автобусларда йөртүне оештыруны;

- балаларның һәм яшьләрнең ял һәм сәламәтләндерү оешмалары җитәкчеләрен һәм педагогик составын хезмәтне саклау, янгын-техник минимумы программалары буенча һәм билгеләнгән тәртиптә барлык хезмәткәрләрнең гигиена әзерлеге буенча укытуны оештыруны;

- Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре буенча министрлык карамагындагы ял оешмаларына юлламалар алган балалар турында мәгълүматны социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасына бирү буенча эшне;

- балаларның һәм яшьләрнең ял һәм сәламәтләндерү оешмаларына кабул итүне түләүсез уздыруны.

- шәхси саклау оешмалары булган балалар һәм яшьләрнең ял һәм сәламәтләндерү оешмаларында лагерь территорияләрен саклауны, җәмәгать тәртибен һәм иминлекне тәэмин итү.

- район лагерьларында ял итүче балаларны һәм яшьләрне сыйфатлы, тулы тукландыруны оештырырга.

3. «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ га:

- көндезге ял лагерьларында 7 яшьтән 18 яшькәчә (18 яшь кереп) балаларның һәм яшьләрнең ялын оештырырга (мәктәп яны лагерьларында);

- балаларның һәм яшьләрнең хезмәт һәм ял лагеры сменаларын оештырырга;

- палатка тибындагы лагерьда 7 яшьтән 18 яшькәчә (18 яшь кереп) балаларның һәм яшьләрнең ялын оештырырга;

- педагоглар составыннан балаларның һәм яшьләрнең ял һәм сәламәтләндерү оешмаларының (көндезге ял лагерьларының (мәктәп яны лагерьларының), хезмәт һәм ял лагерында, палатка тибындагы лагерьда) җитәкчеләр педагогик составын билгеләргә;

- балаларның коллектив ялын оештыручылар тарафыннан Татарстан Республикасы территориясенә аеруча куркыныч инфекцияләр кертүне, төркемле йогышлы авырулар килеп чыгуны кисәтү максатларында, җибәрүгә кадәр кимендә өч тәүлек алдан оештырылган балалар коллективларын республика чикләреннән җибәрүнең планлаштырган вакыты турында Кулланучылар хокукларын яклау һәм кешенең уңай тормышы өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Биектау, Арча, Әтнә, Балтач районнарындагы территориаль бүлегенә хәбәр итәргә;

- Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 331 статьясында каралган

педагогик эшчәнлек белән шөгыльләнүгә каршылыклар булу (булмау) предметына ялны оештыруда эшкә урнашучы (эшләүче) затларны алдан тикшерүләр оештырырга;

- Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы үткәрә торган ялны оештыручыларның квалификациясен күтәрү буенча республика курсларында лагерь җитәкчеләренең һәм тәрбия эшләре буенча урынбасарларның катнашуын тәэмин итәргә;

- сәламәтләндерү оешмаларында балаларны һәм яшьләрне бәхетсезлек очракларыннан ирекле иминләштерүне гамәлгә ашырырга;

- 2025 елда балаларның һәм яшьләрнең ял, сәламәтләндерү һәм эш белән тәэмин итү оешмаларын сәламәтләндерү кампаниясенә әзерләргә һәм кабул итәргә;

- 2025 елның 1 мартына кадәр барлык типтагы лагерьларны ачу графиклары;

- 2025 елның июнь аеннан декабрь аена кадәр, балаларны лагерьга кертүне гамәлгә ашырганнан соң 3 көн эчендә ай саен 25 числога кадәр оператив мәгълүматны;

- практика узу чорында студентларны оештыруда һәм балаларны һәм яшьләрне сәламәтләндерүдә эшкә җәлеп итәргә;

- төзелгән шартнамәләр, дәүләт һәм муниципаль контрактлар нигезендә Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын файдалану турында финанс хисапларын вакытында тапшыруны тәэмин итәргә;

4. Балтач шәһәр җирлеге башкарма комитеты башлыгына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

- лагерьны ачу һәм ябу алдыннан аның әйләнәсендә 500 метр зонаны барьерлы дератизацияләү үткәрүне, лагерь янындагы территорияне алдан энтомологик бәяләү белән кимендә 50 метр арада талпанга каршы (акарицид) эшкәртүне; эшкәртүне үткәргәнче һәм үткәрелгәннән соң 30 көн узгач, дератизация эшкәртүнең нәтиҗәлелеген контрольдә тотуны.

5. Балтач район башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлегенә түбәндәгеләрне оештырырга:

- шәһәр яны ял лагерьларында, шул исәптән Кара диңгез яр буйларында, иҗади сәләтле һәм социаль актив балалар өчен профильле сменаларда һәм төрле тематик юнәлештәге сменаларда балаларның һәм яшьләрнең катнашуын;

- өстәмә гомуми белем бирү программаларын үзләштерүче, иҗади сәләтле һәм социаль актив балалар өчен палатка тибындагы лагерьларның сменаларында балаларның һәм яшьләрнең катнашуын;

- җәйге каникул чорына яшүсмерләр клубы, яшьләр үзәге һәм спорт мәктәбе базасында балалар һәм спорт мәйданчыклары эшен тәэмин итүне;

-«Лето» балаларның һәм яшүсмерләрнең сәламәтләндерүен, ялын һәм эш белән тәэмин ителүен оештыру буенча республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә мәгълүмат тапшырырга:

- балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча йомгаклау финанс хисабын.

- балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан район бюджетына субсидияләр бирү турында ел саен килешүләр төзү эшен;

6. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының мәдәният бүлегенә:

- барлык типтагы лагерьларга күчмә китапханәләр эшен оештырырга;

- Балтач муниципаль районы музейларында җәйге каникуллар вакытында балаларга һәм яшүсмерләргә бушлай керү өчен атнага бер көн билгеләргә;

- барлык типтагы лагерьларда концертлар, дискотекалар, тематик кичәләр оештырырга.

7. Авыр тормыш хәлендә калган балаларның һәм яшьләрнең ялын һәм сәламәтләндерүен оештыру буенча җаваплы башкаручыга түбәндәгеләрне оештырырга:

- авыр тормыш хәлендә калган 7 яшьтән 18 яшькә кадәрге (18 яшьне кертеп) балаларның һәм яшьләрнең стационар лагерьларда, балалар сәламәтләндерү лагерьларында, шифаханә-курорт учреждениеләрендә ялын һәм сәламәтләндерүен;

- авыр тормыш хәлендә калган балалар өчен юлламалар бирүгә ата-аналар (яисә законлы вәкилләре) тарафыннан бирелә торган гаризаларны кабул итүне;

- Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Балтач муниципаль районындагы бүлеге һәм Балтач муниципаль районы балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия тарафыннан бирелгән мәгълүматтан файдаланып, исемлекләрдә күрсәтелгән балаларның булуын раслау һәм ял оешмаларына җибәрелә торган балаларның җыелма исемлеген булдыруны;

- республика лагерьларының исемнәре турында, әлеге категориядәге балалар җибәрелә торган республика лагерьларындагы урыннар һәм сменалар саны, гамәлдәге законнар нигезендә үткәрелә торган ачык конкурс нәтиҗәләре буенча сатып алына торган шәһәр яны лагерьларына юлламалар саны турында мәгълүмат әзерләүне;

8. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Балтач муниципаль районындагы бүлегенә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

- инвалид балаларның һәм сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән 4 яшьтән 18 яшькә кадәрге балаларның ялын оештыру һәм сәламәтләндерү, озатып йөрүне кертеп һәм озатып йөрмичә;

- стационар балалар сәламәтләндерү лагерьларында 7 яшьтән 18 яшькә кадәрге авыр тормыш хәлендә калган балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру һәм сәламәтләндерү.

9. Балтач район башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторына:

-7 яшьтән 18 яшькә кадәрге (18 яшь кереп) ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, опекун һәм тәрбиягә бала алган гаиләләрдә тәрбияләнүче ятим балалар өчен оешмаларда тәрбияләнүчеләрнең ялын оештырырга.

10. Балтач муниципаль районының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе:

- "Балтач район башкарма комитетының мәгариф идарәсе" МКУ балаларны сәламәтләндерү оешмаларына профилактик исәптә җибәрү турында үтенечнамә бирергә;

- 7 яшьтән 18 яшькә кадәрге (18 яшь кереп) палатка тибындагы лагерьда «Галактика балалары» махсус сменасында балаларның ялын оештырырга;

- 7 яшьтән алып 18 яшькәчә (18 яшь кереп) профилактик исәптә торучы балаларның хәрби-патриотик тәрбиягә юнәлдерелгән сменаларда ялын оештырырга;

- 7 яшьтән алып 18 яшькә кадәр (18 яшь кереп) профилактик исәптә торучы балаларның палатка тибындагы лагерьларында махсуслаштырылган сменада балаларның ялын Россия Эчке эшләр министрлыгының Балтач муниципаль районы буенча ГПДН белән берлектә оештырырга.

11. «Балтач РҮХ» ДАССУнә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

- хроник авырулары булган 4 яшьтән 18 яшькә кадәрге (18 яшь кереп), шул исәптән авыр тормыш хәлендә калган балаларның «Балалар» (озатучысыз) яки «Ана һәм бала» (ата-ананың берсе/законлы вәкил белән) юлламалары буенча шифаханәдә дәвалануын оештыруны;

-авыр тормыш хәлендә калган, хроник авырулары булган һәм тернәкләндергеч дәвалауга мохтаҗ 7 яшьтән алып 15 яшькәчә булган балалар өчен шифаханә-курорт оешмаларында шифаханәләрдә дәвалау оештырырга.

- шифаханә-курорт дәвалавына мохтаҗ 30 яшькә кадәрге йөкле хатын-кызларны уздырылган медицина сайлап алуы нигезендә, шифаханәдә булу вакытын тиешенчә кыскартып, шифаханә-курорт дәвалавына «Балалар» юлламасы буенча җибәрүне оештыруны;

- балаларның һәм яшьләрнең ял, сәламәтләндерү һәм эш белән тәэмин итү оешмаларын, гомуми белем бирү учреждениеләре каршындагы көндезге ял (мәктәп яны) лагерьларын, хезмәт һәм ял лагерьларын күрсәтелгән оешмаларны оештыручыларның гаризалары нигезендә медицина кадрлары белән комплектлауны;

- азык-төлек блогы хезмәткәрләре өчен рото-норо вирус һәм эчәк инфекциясе анализларын (бак-посев, лямблия, энтробиоз)да кертеп, балигъ булмаганнарны белем алудан буш вакытта һәм каникуллар вакытында вакытлыча эшкә урнаштыруны рәсмиләштергәндә балигъ булмаганнарның медицина тикшерүләрен һәм балалар сәламәтләндерү оешмаларына эшкә җибәрелә торган персоналның сезонлы тикшерүләрен оештыруны түләүсез нигездә тәэмин итүне;

- ялны оештыру эшенә җибәрелүче персоналга сезонлы тикшерүләр кысаларында флюорография тикшерүләрен һәм антитәнчекләр һәм антигеннар булуга тикшерүне (серообследованиене) түләүсез тәэмин итүне;

- «Аларны башкарганда мәҗбүри башлангыч һәм периодик медицина карап тикшерүләре (тикшерүләр) үткәрелергә тиешле зарарлы һәм (яисә) куркыныч җитештерү факторлары һәм эшләре исемлеген һәм зарарлы һәм (яисә) куркыныч хезмәт шартлары булган авыр эшләрдә эшләүче хезмәткәрләргә мәҗбүри башлангыч һәм периодик медицина тикшерүләре (тикшерүләр) уздыру тәртибен раслау турында» 2011 елның 12 апрелендәге 302н номерлы Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министры боерыгы таләпләре нигезендә Татарстан Республикасы балаларының һәм яшьләренең ялын оештыруга бүлеп бирелә торган акчалар исәбеннән ялны оештыру эшенә юнәлтелүче персоналның түләүсез сезонлы тикшеренүләрен тәэмин итүне;

12. Балтач муниципаль районының «Җәмәгать туклануы» КҖ нә:

- палатка тибындагы лагерьда ял итүче балаларны һәм яшьләрне сыйфатлы, тулы туклandыруны оештырырга.

13. «Балтач районының халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУнә:

- «Мәгариф идарәсе» МКУ белән берлектә 14 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаганнарны укудан буш вакытта һәм каникуллар вакытында эшкә урнаштыру мөмкинлеге турында халыкка мәгълүмат бирү эшен оештырырга;

- балигъ булмаганнарны укудан буш вакытта һәм каникуллар вакытында вакытлыча эшкә урнаштыруны тәэмин итәргә;

- профилактик учетта торучы һәм социаль куркыныч хәлдәге гаиләләрдәге балигъ булмаганнарны беренче чиратта эшкә урнаштыруны тәэмин итәргә.

14. «Балтач муниципаль районы Хуҗалык эксплуатация хезмәте» МБУнә түбәндәгеләрне оештырырга:

- урман-техник чаралар үткәрү (агачларның, куакларның түбән үсүче һәм коры ботакларын кисү, яшь үсенте кисү, үлән чабу, балаларның ял оешмалары территориясеннән коры ауган агачларны һәм чүп-чарны чыгару), дератизация һәм талпанга каршы эшкәрткән һәм чирәме чабылган урыннарга кадәр лагерь тирәли 500 метр радиуста коры ауган агач һәм чүп-чар чыгару һәм бөтен ялны оештыру кампанисе дәвамында, кирәк булган саен;

15. Балтач районы буенча участок урманчысына тәкъдим итәргә:

- 123-ФЗ номерлы Федераль законның 37 статьясы нигезендә балалар сәламәтләндерү лагерын урман массивыннан аера торган янгынга каршы минераллаштырылган полосалар үткәрү.

16. Балтач муниципаль районы Финанс-бюджет палатасына, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының Балтач районы территориаль бүлекчәсенә тәэмин итәргә:

- Татарстан Республикасы бюджеты квотасы нигезендә, балаларның җәйге ялын һәм сәламәтләндерүен финанслау буенча программаның исәп-хисапларын әзерләү;

- Программаны 2025 - елга Балтач муниципаль районы бюджетында сәламәтләндерү кампаниясен оештыру чараларын финанслау өчен каралган акчалар хисабына финансларга;

- республика бюджетыннан бүлеп бирелгән акчаларның максатчан кулланылышын контрольдә тотарга;

- Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын файдалану турында финанс хисапларын вакытында һәр айның 10 нчы, 25 нче числоларына кадәр тапшыру;

17. Балтач муниципаль районының үзәкләштерелгән бухгалтериясенә оештырырга:

- исәп-хисап счетына күчерү юлы белән ата-ана түләвен (взносын) түләүне һәм түләү документларын тапшырганнан соң ата-аналарга яки законлы вәкилләргә юлламалар бирүне оештырырга.

- бухгалтерлык исәбенең тиешле участоклары буенча беренчел документларны вакытында рәсмиләштерүне оештырырга һәм аларны лагерь эшли башлауга әзерләргә;

- хезмәт күрсәтү, биржа мәйданчыгы эше буенча кирәкле шартнамәләрне рәсмиләштерү буенча эшне вакытында башкаруны оештырырга;

- балаларның һәм яшьләрнең җәйге ялын һәм сәламәтлеген финанслау программасы исәп-хисапларын әзерләү, Татарстан Республикасы бюджеты квотасы нигезендә;

- хуҗалык-финанс эшчәнлегенең бухгалтерлык исәбе эшен оештырырга һәм матди, хезмәт һәм финанс ресурсларыннан нәтиҗәле файдалануны, лагерь милкенең сакланышын контрольдә тотуны оештырырга;

18. «Татмедиа» ААҖ филиалы булган «Хезмәт» газетасы редакциясенә һәм «Кайтаваз» ТРК МКУ сәламәтләндерү лагерьлары, көндезге лагерьлар, хезмәт һәм ял лагерьлары эшенең уңай тәҗрибәсен һәм бу өлкәдәге иң актуаль проблемаларны яктыртуны тәкъдим итәргә.

19. Балтач муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ял һәм сәламәтләндерү оешмаларын әзерләп бетерү һәм аларны комплекслы тикшерү буенча эшче төркемгә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

- торак корпусларның, азык-төлек блокларының һәм лагерьны су белән тәэмин итү чыганакларының санитар торышына, мунча-кер юу комплексларының торышына, электр җиһазларының торышына, янгын автоматикасы җайланмаларының, кешеләргә янгын турында хәбәр итү системаларының, телефон элемтәсенең, янгын сүндерүнең беренчел чараларының булуын һәм төзеклеген, шулай ук персоналның янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен белүен тикшерүләргә аерым игътибар итеп, янгын куркынычсызлыгы таләпләрен, санитария кагыйдәләрен, суда кешеләрнең гомерен саклау кагыйдәләрен, хезмәткәрләрнең хезмәтен саклау шартларын һәм торышын, ял итүчеләрнең иминлеген эшләргә һәм җиткерүне;

- барлык таләпләргә туры килүне тикшерү максатыннан, лагерьлар ачылышы алдыннан балаларның һәм яшьләрнең ял һәм сәламәтләндерү оешмаларын комплекслы тикшерүне оештыруны.

20. Түбәндәгеләрне белгеләргә:

- оешмалар персоналының хезмәт хакы, гамәлдәге законнарга каршы килми торган башка финанслау чыганаклары хисабына, эш бирүче тарафыннан арттырылырга мөмкин;

- Россия Федерациясе Салым кодексының 211 статьясындагы 2 пунктының 1 пунктчасы һәм 217 статьясындагы 9 пункты нигезендә барлык дәрәҗәдәге (җирле, региональ, федераль) бюджет акчалары хисабына 16 яшькә җиткән затларга, инвалидлардан тыш, бирелгән сәламәтләндерү оешмаларына юлламаларны тулысынча яисә өлешчә түләү суммасына салым салынырга тиеш.

21. Әлеге карарны Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

22. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе А.Ф. Хәйретдинов

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2024 елның «26» 11
272 номерлы карарына
1 нче кушымта

**«2025 елга Балтач муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүне һәм эш белән тәэмин ителүен оештыру»**
**ПРОГРАММАСЫ**

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | «2025 елга Балтач муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүне һәм эш белән тәэмин ителүен оештыру» программасы (алга таба - Программа) |
| Муниципаль заказ бирүче | Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты |
| Программаны төп эшләүчеләр | «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге |
| Программаның төп башкаручылары | «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе<br>Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге<br>Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Балтач муниципаль районындагы бүлеге<br>«Татарстан Республикасы Балтач районы Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ |
| | Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының мәдәният бүлеге<br>Россия Эчке эшләр министрлыгының Татарстан Республикасы Балтач районы буенча бүлеге<br>«Балтач район үзәк хастаханәсе» ДАССУ<br>Россия Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм бәла-каза нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсенең күзәтчелек эшчәнлеге идарәсенең Балтач һәм Кукмара муниципаль районнары буенча күзәтчелек эшчәнлеге бүлеге |
| | Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы буенча идарәсе<br>Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Мәктәптән тыш эшләр үзәге» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе<br>Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе<br>«Татмедиа» ААҖ филиалы Балтач районы «Хезмәт» газетасы редакциясе |
| Программаның максатлары | Балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру өчен уңайлы шартлар тудыру, аларны каникул вакытында эш белән тәэмин итү, сәламәтләндерү эффекты дәрәҗәсен күтәрү |

| | |
|---|---|
| Программаның бурычлары | - балачакны яклау, балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру, аларның каникул вакытында мәшгульлеген тәэмин итү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру;<br>- сәләтле балаларны, фән олимпиадаларында, иҗади конкурсларда җиңүчеләрне ачыклау, аларга ярдәм итү системасын формалаштыру; балалар һәм яшьләр иҗтимагый оешмаларына, волонтерларга ярдәм итү, ятим балаларга, ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларга дәүләт ярдәме күрсәтү; балалар авыруын һәм инвалидлыкны профилактикалау; балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау;<br>- тормыш-көнкүрешне яхшырту һәм имин булмаган балаларның проблемаларын хәл итү;<br>- балаларның һәм яшьләрнең ял итү инфраструктурасын саклау һәм ныгыту;<br>- сәламәтлекне ныгыту, тулы физик үсешкә ярдәм итү.<br>- авыр тормыш хәлендәге балаларны нәтиҗәле комплексלы социаль яклауны һәм җәмгыятькә интеграцияләүне формалаштыру;<br>- сәламәтләндерү учреждениеләрен персонал белән комплектлауны тәэмин итү. |
| Программаны гамәлгә ашыру вакыты һәм этаплары | 2025 елның гыйнвары-декабре |
| Программа чаралары исемлеге | 1. Көндезге ял (мәктәп яны) лагерьларында балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру<br>2. Балаларның һәм яшьләрнең көндезге ял һәм хезмәт лагерьларында сменаларны оештыру.<br>3. Палатка тибындагы лагерьда профильле сменаларда балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру<br>4. Авыр тормыш хәлендә булган балалар һәм яшьләр өчен лагерьда балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру<br>5. Профилактик исәптә торучы балаларның махсус сменада ялын оештыру. |
| Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | 2025елга Программаны финанслауның гомуми күләме<br>5547,0 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>шул исәптән авыр тормыш хәлендә калган балалар һәм яшьләр категориясен финанслауга-561,7 мең сум;<br>Татарстан Республикасы бюджеты акчалары – 5491,5 мең сум;<br>җирле бюджет акчалары – 55,5 мең сум |
| Программаны гамәлгә ашыруның көтелгән соңгы нәтиҗәләре (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм анық бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | 7 яшьтән 18 яшькә кадәрге балаларның гомуми санынан 60 процентган да ким булмаган өлешен каникул вакытында төрле ял формалары белән тәэмин итү.<br>Ял сыйфатын һәм сәламәтләндерү дәрәҗәсен күтәрү, барлык программа чаралары киселешендә ачык чагылыш тапкан 80 процентган да ким булмаган сәламәтләндерү нәтиҗәлелегенә (эффектына) ирешү. Лагерь тормышында катнашу процессында балаларның һәм яшьләрнең үз билгеләнешен табуы (самореализация), үсеше һәм камилләшүе |

**1.Кереш**

Программа 2025 елга балаларның һәм яшүсмерләрнең ялын, сәламәтләндерүен һәм эш белән тәэмин ителүен оештыру өчен кирәкле хокукый, оештыру һәм икътисадый шартлар тудыру максатыннан эшләнгән.

Җәйге каникуллар балаларның һәм яшүсмерләрнең буш вакытының зур өлешен

тәшкил итә. Бу чор аларның иҗади потенциалын үстерү, шәхес мөмкинлекләрен камилләштерү, мәдәният кыйммәтләренә тарту, социаль элемтәләр системасына керү, үз планнарын тормышка ашыру, эшчәнлекнең шәхси әһәмиятле өлкәләрендә шәхси мәнфәгатьләрне канәгатьләндерү өчен уңайлы. Хәзерге вакытта мәгариф системасында ял итү – ул иҗади үсеш, укучыларның рухи дөньясын һәм интеллектын баету, аларны социальләштерү һәм һөнәри юнәлеш бирү өчен киңәйтелгән мөмкинлекләр. Җәйге ял системасының тәрбия кыйммәте балаларның көндезге сәламәтләндерү җәйге лагерьлары, профильле сменалы шәһәр читендәге лагерьлар яшүсмерләрнең һәм яшьләрнең педагогик яктан максатчан, эмоциональ яктан җәлеп итүчән яллары, аларның сәламәтлеген торгызу, яңа тәэсирләргә ихтыяҗларны канәгатьләндерү, үз-үзеңне иҗади яктан булдыру һәм аралашу өчен барлык кирәкле шартларны тудыруында. Программа Балтач муниципаль районының балаларның һәм яшүсмерләрнең ялын, сәламәтләндерүен һәм эш белән тәэмин ителүен оештыруның төп юнәлешләрен һәм формаларын билгели. Бу эшчәнлек балаларның сәламәтлеген саклауга һәм ныгытуга, яшь буынга әхлакый, рухи һәм патриотик тәрбия бирүгә, балаларда һәм яшьләрдә танып белү активлыгын, иҗади потенциалны, физик һәм интеллектуаль сәләтләрне үстерүгә, балигъ булмаганнарның караучысызлыгын һәм хокук бозуларын профилактикалауга юнәлдерелгән системалы характерга ия.

Балалар һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен, мәшгульлеген оештыру һәрвакыт социаль өлкә эшенең өстенлекле юнәлешләреннән берсе булды һәм булып кала бирә. Муниципаль районда балаларның каникул чорында сәламәтләндерү, ял итү һәм мәшгульлек итүнең нәтиҗәле формалары формалашкан, шуңа күрә соңгы биш ел дәвамында сәламәтләндерү кампаниясе йомгаклары буенча уңай динамика күзәтелә. Балаларны барлык төр ял белән тәэмин итү арта бара. Ел саен районда балалар белем бирү оешмалары базасында көндезге ял итү лагерьларында 7 яшьтән 18 яшькә кадәрге (18 яшь кереп) балаларның 30%тан артыгы ял итә.

Көндезге ял лагереның төп идеясе - һәр балага үзләренең иҗади һәм оештыру сәләтләрен күрсәтергә, педагоглары, яшьтәшләре белән теге яки бу мәсьәләләр буенча уртак фикер алышу аша балаларның аралашу даирәсен киңәйтергә мөмкинлек бирә.

2024 елгы сәламәтләндерү кампаниясе чорында 1300 бала һәм яшь кеше ял иткән. Район территориясендә 1120 баланы үз эченә алган 15 көндезге лагерь, 135 баланы һәм яшь кешене үз эченә алган «Балтач гимназиясе» МББУ территориясендә палатка тибындагы лагерь, 20 баланы үз эченә алган көндезге хезмәт һәм ял лагере эшли.Авыр тормыш хәлендә калган балаларның ялын һәм эш белән тәэмин ителүен оештыруга зур игътибар бирелә. Авыр тормыш хәлендә булган балалар һәм яшьләр өчен лагерьда балалар һәм яшьләр өчен 15 балага ял оештырылды, профилактик исәптә торучы балалар өчен махсус сменада 10 балага Мамадыш шәһәрендә ял оештырылды. «Романтик» балалар җәйге сәламәтләндерү лагере капиталь төзекләндерүдә.

Халыкны эш белән тәэмин үзәге дәүләт учреждениесе аша аз керемле һәм социаль куркыныч гаиләләрдән 251 яшүсмер эшкә урнаштырылган, шуларның 8 е – Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссиядә, Эчке эшләр бүлегенең балигъ булмаганнар эшләре бүлегендә исәптә торучы, алар район территориясен төзекләндерү буенча эш алып барганнар.

Балтач районында балаларның һәм яшүсмерләрнең ялын һәм сәламәтләндерүен оештыруның һәм тәэмин итүнең өстенлекле юнәлешләре билгеләнгән:

- сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру;
- авыр тормыш хәлендә калган балаларның һәм яшүсмерләрнең, шул исәптән профилактик исәптә торучы балигъ булмаганнарның ялын һәм сәламәтләндерүен оештыру;
- хезмәт белән тәэмин ителүен оештыру;
- аз чыгымлы ял формаларын үстерү;
- методик яктан һәм кадрлар белән тәэмин итү;
- ял инфраструктурасын һәм аның формаларын камилләштерү;
- балаларның ялын һәм сәламәтләндерүен оештыручы учреждениеләрдә комплекслы

тормыш һәм сәламәтлек иминлеген тәэмин итү;

- ял һәм сәламәтләндерү хезмәтләре күрсәтүче учреждениеләрнең матди-техник базасын ныгыту.

Профилактика системасының барлык органнарның ведомствоара хезмәттәшлеген, эшчәнлеген контрольдә тотуны һәм координацияләүне Балигъ булмаганнарның ялын, сәламәтләндерүен һәм эш белән тәэмин ителүен оештыру буенча ведомствоара комиссия тәэмин итә. Ведомствоара комиссия ел әйләнәсендә даими нигездә эшли. Ел саен, йомгак ясап, комиссия сәламәтләндерү оешмалары эшчәнлеген оештырудагы проблемалы мәсьәләләрне билгели, киләсе елга перспектив чаралар планын төзи. Утырышлар арасында актуаль проблемаларны оператив хәл итү өчен эшче төркем эшли, ул җәйге ялны һәм сәламәтләнүне тәэмин итүче хезмәтләр һәм ведомстволардан тора.

## 2. Программаның максаты һәм төп бурычлары

Максат: балигъ булмаганнарның ялын, сәламәтлеген ныгыту, шәхси үсешен һәм мәшгульлеген тәэмин итү өчен оптималь шартлар тудыру.

Бурыч:

- балаларның һәм яшүсмерләрнең ялын, сәламәтләндерүен һәм эш белән тәэмин ителүен оештыруны җайга салучы норматив-хокукый база булдыру;
- санитар-гигиена нормаларын һәм кагыйдәләрен үтәү өчен шартлар тудыру, җәйге вакытта эпидемиологик һәм янгынга каршы куркынычсызлыкны, террорчылыкка каршы якланган булуны тәэмин итү;
- 2025 елның сәламәтләндерү чорында балаларның һәм яшүсмерләрнең физик үсеше, сәламәтлекләрен ныгыту, иҗади сәләтләрен үстерү, сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру өчен чаралар системасын булдыру;
- сәламәтләндерү чорында балаларның ялын, сәламәтләндерүен һәм эш белән тәэмин ителүен оештыру буенча ведомствоара хезмәттәшлекне тәэмин итү;
- балалар һәм яшүсмерләр мохитендә җәмгыятькә каршы (асоциаль) күренешләрне, имгәнүләрне профилактикалау эшен оештыру.
- авыр тормыш хәлендә булган балаларның, мөмкинлекләре чикле балаларның, профилактик учетта торучы балаларның ялын һәм сәламәтләндерүен тәэмин итү.
- балалар ялын оештыруның аз чыгымлы формаларын үстерү.

## 3. Программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү

2025 елга Программаны финанслауның гомуми күләме 5547,0 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:

шул исәптән авыр тормыш хәлендә калган балалар һәм яшьләр категориясен финанслауга-561,7 мең сум;

Татарстан Республикасы бюджеты акчалары – 5491,5 мең сум;

җирле бюджет акчалары – 55,5 мең сум

Программа чараларын гамәлгә ашыруга бүлеп бирелә торган акчаларның максатчан кулланылышын Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы финанс-бюджет палатасы тикшерә.

## 4. Программаны гамәлгә ашыру механизмы

2025 елда балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыруда катнашучы Балтач район башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлегенә, «Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУсына түбәндәгеләрне тапшырырга тәкъдим ителә:

«Лето» балаларның һәм яшүсмерләрнең сәламәтләндерүен, ялын һәм эш белән тәэмин ителүен оештыру буенча республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә:

2025 елның 1 мартына кадәр - барлык төр лагерьларны ачу графигын;

2025 елның маеннан декабренә кадәр (декабрьне дә кертеп), балалар һәм яшьләр сәламәтләндерү учреждениеләренә кергәннән соң өч көнлек срокта - оператив мәгълүматны һәм ай саен 25 числога кадәр – балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру турында мониторингны;

20 августка кадәр - үткәрелгән чаралар турында фото- һәм видеоматериаллар булган иҗади хисаплар;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән Министрлыгына:

2025 елның мартына кадәр - көндезге мәктәп яны лагерьларын, көндезге ял һәм хезмәт лагерьларын ачу графикларын;

2025 елның мартыннан декабренә кадәр, балалар һәм яшьләр сәламәтләндерү учреждениеләренә кергәннән соң өч көн эчендә, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан билгеләнгән формалар буенча - оператив мәгълүматны һәм ай саен 25 числога кадәр - көндезге ял лагерьларында (мәктәп яны), көндезге ял һәм хезмәт лагерьларында (мәктәп яны), палатка тибындагы лагерьда балаларның ялын оештыру турында ай саен йомгаклау мәгълүматын.

Балтач муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру түбәндәге формаларда башкарыла:

- балаларның һәм яшьләрнең көндезге ял (мәктәп яны) лагерьларында балаларның һәм яшьләрнең ялы;
- балаларның һәм яшьләрнең хезмәт һәм ял лагерьларында ялы;
- балаларның һәм яшьләрнең палатка тибындагы лагерьда ялы;
- авыр тормыш хәлендә булган балалар һәм яшьләр өчен лагерьда балаларның һәм яшьләрнең ялы;
- профилактик исәптә торучы балаларның махсус сменада ялы;
- балалар һәм яшьләрнең шифаханә-курорт оешмаларында ял итүе.

## 5. Программаны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре

- 7 яшьтән 18 яшькә (18 яшь кереп) кадәрге балаларның гомуми санынннан 60 процenttан да ким булмаган өлешен каникул вакытында төрле ял формалары белән тәэмин итү.
- ял сыйфатын һәм сәламәтләндерү дәрәҗәсен күтәрү, барлык программа чаралары киселешендә ачык чагылыш тапкан 80 проценттан да ким булмаган сәламәтләндерү нәтиҗәлелегенә (эффектына) ирешү;
- балаларның һәм яшьләрнең сәламәтлеген ныгыту;
- балаларда һәм яшьләрдә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә кызыксыну уяту;
- төрле яшьтәге балалар арасында дуслыкны һәм хезмәттәшлекне ныгыту;
- балаларда һәм яшьләрдә әхлакый тәрбия дәрәҗәсен күтәрү;
- шәхси иминлек һәм тирә-юньдәгеләрнең иминлеге өчен җаваплылык хисе тәрбияләү;
- лагерь тормышында катнашу процессында балаларның һәм яшьләрнең үз билгеләнешен табуы (самореализация), үсеше һәм камилләшүе.

Әлеге программа кысаларында хезмәт күрсәтү күләмнәренең расланган нормативлары нигезендә үткәрелә торган чаралар

| № | Чаралар исеме | Үткәрү вакытлары | Башкаручы |
|---|---|---|---|
| 1 | «Балтач муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен һәм эш белән тәэмин | Ноябрь 2024 ел | «Мәгариф идарәсе» МКУ, Балтач район башкарма комитеты яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | ителүен оештыру турында» карарны эшләү һәм раслау | | |
| 2 | Сәламәтләндерү кампаниясен оештыручылар өчен республика семинарында катнашу | Март, ноябрь 2025 ел | «Балтач район башкарма комитеты Мәгариф идарәсе» МКУ |
| 3 | Балаларның һәм яшьләрнең ялын һәм сәламәтләндерүен гамәлгә ашыручы учреждениеләрне Татарстан Республикасы лагерьлары реестрына кертү | Апрель 2025 ел | «Балтач район башкарма комитеты Мәгариф идарәсе» МКУ |
| 4 | Сәламәтләндерү кампаниясенә әзерләнү | Ел дәвамында | Балтач район башкарма комитеты, «Балтач район башкарма комитеты Мәгариф идарәсе» МКУ |
| 5 | Җәйге һәм көзге чорда сәламәтләндерү кампаниясен оештыру буенча кирәкле документлар әзерләү | Ел дәвамында | «Балтач район башкарма комитеты Мәгариф идарәсе» МКУ |
| 6 | Балаларның ял һәм сәламәтләндерү оешмалары хезмәткәрләре өчен медицина тикшерүләре уздыру | Май 2025 ел | «Балтач район башкарма комитеты Мәгариф идарәсе» МКУ, Балтач районының «Район үзәк хастаханәсе» ДАССУ |
| 7 | Барлык төрдәге лагерьлар өчен санитар-эпидемиологик нәтиҗәләр алу өчен документлар әзерләү | Май 2025 ел | «Балтач район башкарма комитеты Мәгариф идарәсе» МКУ |
| 8 | Җәйге сәламәтләндерү кампаниясен уздыру турында документларны һәм мәгълүматны муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында урнаштыру | Май 2025 ел | Балтач район башкарма комитеты Мәгариф идарәсе» МКУ |
| 9 | Массакүләм мәгълүмат чараларында җәйге сәламәтләндерү кампаниясен үткәрүнең барышы | Июнь-август 2025 ел | «Тамедиа» ААҖ филиалы «Хезмәт» редакциясе, «Кайтаваз» ТРК МКУ |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | турында мәгълүмат урнаштыру | | |
| 10 | Лагерьларны кабул итү актларын әзерләү | Май, 2025 ел | «Мәгариф идарәсе» МКУ |
| 11 | Гомуми белем бирү мәктәпләре укучыларының көндезге ял (мәктәп яны) лагерьларда ялын һәм сәламәтләндерүен оештыру | Июнь, ноябрь 2025 ел | «Мәгариф идарәсе» МКУ |
| 12 | Хезмәт һәм ял лагерьларында сменалар оештыру | Июнь, 2025 ел | «Мәгариф идарәсе» МКУ |
| 13 | Палаткалы лагерьда профильле сменалар оештыру | Июнь-август, 2025 ел | «Балтач район башкарма комитеты Мәгариф идарәсе» МКУ |
| 14 | Авыр тормыш хәлендә булган балаларның ялын оештыру | Июнь-август, 2025 ел | «Балтач район башкарма комитеты Мәгариф идарәсе» МКУ, Балтач район башкарма комитеты яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Балтач муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге |
| 15 | Профилактик исәптә торучы балалар өчен махсус смена оештыру | Июль, 2025 ел | Балтач районы балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия, балигъ булмаганнар эшләре бүлеге |
| 16 | Балигъ булмаганнарны укудан буш вакытта һәм каникуллар вакытында эшкә урнаштыру | Июнь-август, 2025 ел | «Балтач районы Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ, «Балтач район башкарма комитеты Мәгариф идарәсе» МКУ |

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2024 елның «26» 11
272 номерлы карарына
2 нче кушымта

**Балтач муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен һәм эш белән тәэмин ителүен оештыру турында НИГЕЗЛӘМӘ**

**1. Гомуми нигезләмәләр**

1.1. Әлеге Нигезләмә Балтач муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру механизмын һәм Балтач муниципаль район башкарма хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының, дәүләт һәм дәүләтнеке булмаган учреждениеләрнең, Балтач муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыруда катнашучы оешмаларның һәм гражданнарның үзара хезмәттәшлеге тәртибен билгели.

1.2. Балтач муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен һәм эш белән тәэмин ителүен оештыру буенча вәкаләтле орган булып Балтач муниципаль районы балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча ведомствоара комиссия тора. Балаларның һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен һәм эш белән тәэмин ителүен оештыру буенча ведомствоара комиссия составы һәм нигезләмәсе Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карары белән раслана.

1.3. Әлеге Нигезләмә кысаларында балаларның һәм яшьләрнең ялы дигәндә каникуллар вакытында балаларда һәм яшьләрдә шәхеснең белем һәм иҗат потенциалын үстерүне, сәламәтлекне саклауны һәм ныгытуны, авыруларны профилактикалауны, организмны чыныктыруны, сәламәт яшәү рәвеше күнекмәләрен формалаштыруны, балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалауны, өлешчә яисә тулысынча Татарстан Республикасы бюджеты хисабына финанслана торган иҗтимагый файдалы һәм җитештерүчәнлек хезмәте, физик культура, спорт, туризм белән шөгыльләнүне тәэмин итә торган шартлар һәм чаралар комплексы аңлашыла.

**2. Балаларның һәм яшьләрнең ялы һәм сәламәтләндерү формалары**

2.1. Балтач муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру түбәндәге формаларда башкарыла:

палатка тибындагы лагерьда смена;

балаларның һәм яшьләрнең көндезге ял лагерында смена;

хезмәт һәм ял лагерында смена;

профилактик исәптә торучы балалар өчен махсус смена.

2.2. Палатка тибындагы лагерьда смена - балаларның иҗади потенциалын үстерү, табигый шартларда булуның практик күнекмәләрен алу, физик культура, туризм, туган якны өйрәнү, уку-тикшеренү һәм башка эшчәнлек төрләре белән шөгыльләнү максатыннан, ял һәм сәламәтләндерү, аларның сәламәтлеген ныгыту формасы. Җәйге каникулларда сменаның озынлыгы 7 көннән дә ким булмаска тиеш.

2.3. Белем бирү оешмасы тарафыннан оештырылган көндезге лагерьда смена - каникуллар чорында укучылар һәм тәрбияләнүчеләр өчен тукландыруны мәҗбүри оештырып, көндезге вакытта күбесенчә мәгариф оешмасы базасында үтүче мәгариф оешмалары укучылары белән ял итү һәм белем бирү эшчәнлеге формасы. Сменаның дәвамлылыгы җәйге чорда 21 календарь көннән дә, көзге, кышкы һәм язгы каникулларда - җиде көннән дә ким булмаска тиеш.

2.4. Хезмәт һәм ял лагерында смена - ул каникуллар чорында тукклануны тәэмин итеп, көндезге вакытта күбесенчә мәгариф оешмалары базасында үтүче иҗтимагый файдалы хезмәт оештыру белән ял итү формасы. Сменаның озынлыгы-18 календарь көн.

2.5. Лагерьларда отрядлар балаларның яшен һәм мәнфәгатьләрен исәпкә алып туплана. Отрядларның саны лагерьларны булдыруга, карап тотуга һәм аның эш режимын оештыруга карата санитар-эпидемиологик таләпләр белән билгеләнгән нормативлар нигезендә билгеләнә.

**3. Балаларның һәм яшьләрнең ял итү һәм сәламәтләндерү кампанияләрендә катнашучылар**

3.1. Сәламәтләндерү ял кампанияләрендә Балтач муниципаль районы территориясендә даими яшәүче 7-18 яшьлек (18 яшьне кертеп) балалар катнаша.

3.2. Балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру түбәндәге категория балалар һәм яшьләр киселешендә башкарыла:

- гомуми белем бирү учреждениеләре укучылары;

- иҗади сәләтле балалар, волонтерлар, балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре активы әгъзалары, балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләр;

- республика, бөтенроссия, халыкара конкурслар, ярышлар һәм олимпиадалар җиңүчеләре һәм призерлары;

- хроник авырулары булган, торгызу дәвалавына мохтаҗ, шул исәптән ата-аналарының берсе (яисә законлы вәкилләре) белән бергә 4 яшьтән 18 яшькә кадәрге (18 яшьне кертеп) балалар;

- Эчке эшләр органнарының балигъ булмаганнар эшләре буенча бүлекчәләрендә һәм балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссияләрдә ведомствоара профилактик учетта торучы балалар (алга таба-профилактик исәптә торучы балалар);

- авыр тормыш хәлендә калган балалар, шул исәптән:

ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар оешмаларында тәрбияләнүчеләр, опекун һәм тәрбиягә бала алган гаиләләрдә тәрбияләнүче 7 яшьтән 18 яшькә кадәрге ятим балалар;

4 яшьтән 18 яшькә кадәрге(18 яшьне кертеп) инвалид балалар һәм сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар озатып йөрү белән һәм озатып йөрүчесез;

социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләрдәге 7 яшьтән 18 яшькә кадәрге(18 яшьне кертеп) балалар;

тәртибе девиант булган укучылар өчен мәгариф оешмаларында торучы (профилактик исәптә торучы) 7 яшьтән 18 яшькә кадәрге (18 яшьне кертеп) балалар;

килеп туган хәлләр нәтиҗәсендә тормышлары объектив рәвештә бозылган балалар, әлеге хәлләрне балалар мөстәкыйль рәвештә яисә гаилә ярдәмендә җиңә алмаганда, 7 яшьтән 18 яшькә кадәрге чорда(18 яшьне кертеп);

тормыш эшчәнлеге объектив рәвештә бозылган балалар

әлеге хәлләрне мөстәкыйль рәвештә яисә гаилә ярдәме белән, 7 яшьтән алып 18 яшькәчә булган хәлләр;

җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән түбәнрәк булган, балага айлык пособие алучы (аз керемле һәм аз керемле гаиләләр) гаиләләрдән 7 яшьтән 15 яшькә кадәрге(15 яшьне кертеп) балалар.

**4. Балаларның һәм яшьләрнең ял итү һәм сәламәтләндерү сменаларын оештыручылар**

4.1. Балаларның һәм яшьләрнең ял һәм сәламәтләндерү сменаларын оештыручылар булып Балтач район башкарма комитетының структур бүлекчәләре тора.

4.2. Балтач районы Башкарма комитетының һәм Балтач муниципаль районының структур бүлекчәләре иҗади сәләтле актив балалар һәм яшьләр өчен, авыр тормыш хәлендә калган балалар өчен, 7 яшьтән 18 яшькә кадәрге (18 яшьне кертеп) профилактик исәптә торучы балалар өчен, хроник авырулары булган, тернәкләндергеч дәвалауга мохтаҗ балалар өчен, шул исәптән ата-аналарының берсе белән бергә, ятим балалар өчен һәм опекунлык һәм тәрбиягә бала алган гаиләләрдә тәрбияләнүче ятим балалар өчен ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, 7 яшьтән 18 яшькә кадәрге балалар һәм яшьләр өчен көндезге лагерьларда (мәктәп яны), хезмәт һәм ял лагерьларында, палатка тибындагы лагерьларда сменалар оештыручы булып тора.

## 5. Балаларның һәм яшьләрнең ялын һәм сәламәтләндерүен оештыруны финанслау тәртибе

5.1. Балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыруны финанслау түбәндәге чыганаклардан башкарыла:

Татарстан Республикасы бюджеты акчалары;

ата-аналарның фаразланган акчалары;

җирле бюджет акчалары;

гамәлдәге законнарда каралган башка чыганаклар.

5.2. Балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыруны Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән финанслау Балтач муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә финанс чыгымнары нормативлары нигезендә Балтач муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыруга хезмәт күрсәтү күләме чикләрендә гамәлгә ашырыла. Чираттагы финанс елына балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыруга финанс чыгымнары нормативлары балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру формалары киселешендә, балаларның һәм яшьләрнең ял итү кампаниясендә катнашучы бер кешегә исәпләгәндә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

5.3. Балтач муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыруга хезмәт күрсәтү күләме нормативлары, сменаларны оештыручылар һәм балаларның һәм яшьләрнең ял кампаниясендә катнашучылар киселешендә, ел саен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

Балтач муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыруга хезмәт күрсәтү күләмнәре нормативларын исәпләү, Балтач муниципаль районындагы халыкның демографик үзенчәлекләрен, структурасын һәм мохтаҗлыгының факттагы дәрәҗәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана торган Балтач муниципаль районындагы социаль хезмәтләр (инфраструктура) белән тәэмин ителешнең социаль гарантияләре дәрәҗәсе нигезендә башкарыла.

5.4. Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешмаларда тәрбияләнүчеләрнең, хроник авырулары булган балаларның, шул исәптән ата-ананың (яисә законлы вәкилләрнең) берсе белән бергә, профилактик исәптә торучы балаларның, республика, бөтенроссия, халыкара конкурслар, ярышлар һәм олимпиадаларда җиңүчеләрнең һәм призерларның ялын оештыру Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән финанслана.

5.5. Балалар һәм яшьләрнең көндезге лагерьларда (мәктәп яны лагерьларында), хезмәт һәм ял лагерьларында, палатка тибындагы лагерьларда ялын оештыру Татарстан Республикасы бюджеты һәм җирле бюджет акчалары исәбеннән финанслана.

## 6. Балаларның һәм яшьләрнең ялы һәм сәламәтләндерүе өчен ата-аналар түләве күләмен билгеләү тәртибе

6.1. Сәламәтләндерү учреждениеләрендә ял иткән өчен ата-аналар түләве күләме балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыруга финанс чыгымнары нормативының кимендә 15 проценты күләмендә (барлык төр сменаларны оештырганда), ләкин юлламаның факттагы

бәясеннән 50 проценттан да артмаган күләмдә (республикакүләм профильле сменаларны оештырганда) билгеләнә.

6.2 Оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрнең үзкыйммәтенә тигез чыгымнарны чагылдыручы юллама бәясе билгеләнә. Норматив чыгымнар реаль чыгымнарга туры килмәсә, юлламаның фактгагы бәясе һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан бүленә торган акчаларның өлеше арасындагы аерма ата-аналар (яки законлы вәкилләр), оешмалар тарафыннан түләнә.

## 7. Көндезге ял (мәктәп яны) лагеренда балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру тәртибе

7.1. Мәгариф оешмасы оештырган көндезге ял (мәктәп яны) лагерена ата-аналар (законлы вәкилләр) гаризасы нигезендә мәгариф оешмаларында белем алучы укучылар җибәрелә.

7.2 Ата-аналар гаризасы мәгариф оешмасы директоры тарафыннан расланган форма буенча бала белем алган мәгариф оешмасына тапшырыла.

7.3 Мәгариф оешмасы ата-аналар (законлы вәкилләр) гаризасы нигезендә көндезге лагерьга җибәрелә торган балалар исемлеген формалаштыра.

7.4. Исемлектә күрсәтелә:

баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме;

гариза биргән ата-ананың (яки законлы вәкиленең) фамилиясе, исеме, атасының исеме;

баланың туган елы, ае, көне, җенесе;

ата-ананың (яки законлы вәкилнең) эш урыны;

бала белем ала торган мәгариф оешмасы исеме;

бала укый торган сыйныф.

7.5. Мәгариф оешмасы тарафыннан оештырылган көндезге ял (мәктәп яны) лагерьларында балаларның ялын оештыру планы Балтач район башкарма комитеты тарафыннан тиешле финанс елына расланган муниципаль районның көндезге ял (мәктәп яны) лагерьларында балаларның һәм яшьләренең ялын оештыруга хезмәт күрсәтү күләме нормативлары чикләрендә төзелә һәм түбәндәгеләрне үз эченә ала:

базаларында лагерьлар оештырылачак мәгариф оешмалары исемнәре;

мәгариф оешмалары киселешендә лагерьларда оештырылган урыннар саны;

мәгариф оешмалары киселешендә оештырыла торган лагерьларда сменалар саны һәм аларның дәвамлылыгы;

балаларны базаларында лагерьлар оештырылачак мәгариф оешмалары буенча бүлү.

7.6. Мәгариф оешмасы оештырган көндезге ял (мәктәп яны) лагерьларында балаларның ялын оештыру планы Балтач район башкарма комитеты карары белән җәйге һәм көзге сәламәтләндерү кампанияләре өчен аерым раслана.

7.7. Өч көн эчендә «Балтач район башкарма комитет Мәгариф идарәсе» МКУ Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына ял итү оешмаларына килгән балалар саны турында мәгълүмат җибәрә.

7.8 Ай саен, 25 числога кадәр, Балтач район башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы адресына, ял иткән балалар санын һәм балаларның ялын оештыруга бүлеп бирелгән акчаларны күрсәтеп, ял итүне оештыру турында мониторинг җибәрә.

7.9 Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе, Мәгариф оешмасы оештырган көндезге лагерьда ял беткәннән соң җиде көн эчендә, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы адресларына лагерьларда башкарылган эшләр турында мәгълүматны җибәрә.

## 8. Хезмәт һәм ял лагерьларында сменаны оештыру тәртибе

8.1. Хезмәт һәм ял лагерьларына иҗтимагый-файдалы хезмәткә җәлеп итү максаты белән гомуми белем бирү оешмалары укучылары җибәрелә.

Гомуми белем бирү оешмасы ата-аналар (законлы вәкилләр) гаризалары нигезендә хезмәт һәм ял лагерьларына җибәрелә торган гомуми белем бирү оешмасы балаларының исемлеген һәм хезмәт һәм ял лагерьларында аларның ялын оештыру планын формалаштыра.

8.2. Исемлектә күрсәтелә:

баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме,

гариза биргән ата-ананың (законлы вәкиленең) фамилиясе, исеме, атасының исеме;

баланың туган елы, ае, көне, җенесе;

ата-ананың (законлы вәкилнең) эш урыны;

бала укый торган гомуми белем бирү оешмасы исеме;

бала укый торган сыйныф.

8.3. Хезмәт һәм ял лагерьларында балаларның ялын оештыру планы Балтач район башкарма комитеты тарафыннан тиешле финанс елына расланган муниципаль районның балаларының һәм яшьләренең ялын оештыруга хезмәт күрсәтү күләме нормативлары чикләрендә төзелә һәм түбәндәгеләрне үз эченә ала:

базаларында хезмәт һәм ял лагерьлары оештырылачак гомуми белем бирү оешмаларының исеме;

мәгариф оешмалары киселешендә хезмәт һәм ял лагерьларында оештырылган урыннар саны;

мәгариф оешмалары киселешендә оештырыла торган хезмәт һәм ял лагерьларында сменалар саны һәм аларның дәвамлылыгы;

балаларны базаларында хезмәт һәм ял лагерьлары оештырылачак мәгариф оешмалары буенча бүлү.

8.4. Хезмәт һәм ял лагерьларында балаларның ялын оештыру планы Балтач район башкарма комитеты карары белән җәйге һәм көзге сәламәтләндерү кампанияләре өчен аерым раслана.

8.5. «Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ өч көн эчендә Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы адресына ял итү оешмаларына килгән балалар саны турында мәгълүмат җибәрә.

8.6. Ай саен, 25 числога кадәр, Балтач район башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы адресына, ял иткән балалар санын һәм балаларның ялын оештыруга бүлеп бирелгән акчаларны күрсәтеп, ял итүне оештыру турында мониторинг җибәрә.

8.7. «Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ хезмәт һәм ял лагерьларында сменалар тәмамланганнан соң җиде көн эчендә, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы адресларына хезмәт һәм ял лагерьларының эшчәнлеге турында мәгълүматны җибәрә.

## 9. Авыр тормыш хәлендә булган балаларның ялын оештыру тәртибе

9.1. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты тарафыннан билгеләнгән җаваплы башкаручы авыр тормыш хәлендә булган балалар өчен юлламалар бирү өчен ата-аналар (яки аларның законлы вәкилләре) тарафыннан бирелгән гаризаларны кабул итә.

9.2. Алынган гаризалар нигезендә җаваплы башкаручы балалар исемлекләрен төзи һәм Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының «Лето» балаларның һәм яшүсмерләрнең сәламәтләндерүен, ялын һәм эш белән тәэмин ителүен оештыру буенча республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә тапшыра.

9.3. Җаваплы башкаручы, Балтач муниципаль районындагы Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Социаль яклау бүлеге биргән мәгълүматтан файдаланып, исемлектә күрсәтелгән балаларның булуын раслый һәм ял итү оешмаларына җибәрелә торган балаларның җыелма исемлеген төзи.

9.4. Авыр тормыш хәлендә калган балаларның ялын оештыру планы «Балтач район башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ тарафыннан төзелә һәм республика лагерьларының исемнәре турында мәгълүмат, әлеге категориядәге балалар җибәрелә торган

республика лагерьларында урыннар һәм сменалар саны, ачык конкурс йомгаклары буенча сатып алына торган шәһәр яны лагерьларына юлламалар саны туплана.

9.5. Балаларның ялын һәм сәламәтләндерүен оештыру планы «Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ боерыгы белән расланa.

## 10. Шәһәр читендәге лагерьларының, палатка тибындагы лагерьларның, шул исәптән Кара диңгез ярларында профильле сменаларында һәм профилактик исәптә торучы балалар өчен профильле сменаларда балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру тәртибе

10.1. Шәһәр читендәге лагерьларның, палатка тибындагы лагерьларның, шул исәптән Кара диңгез ярында, профильле сменаларында катнашу өчен республика, бөтенроссия, халыкара конкурсларда, ярышларда һәм олимпиадаларда җиңүчеләр һәм призерлар, иҗади сәләтле балалар, волонтерлар, балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре активы әгъзалары, өстәмә гомуми белем бирү программаларын үзләштерүче укучылар, Татарстан Республикасының халыкара һәм региональара килешүләрен гамәлгә ашыру кысаларында Россия Федерациясе субъектларыннан һәм якын һәм ерак чит илләрдән җибәрелә торган балалар һәм яшьләр җибәрелә.

10.2. Профильле сменаларда катнашучылар профильле сменада катнашучыдан яисә профильле сменада катнашучы балигъ булмаган бала өчен атасыннан яисә анасыннан (яисә законлы вәкилләрдән) гариза нигезендә шәһәр яны лагерьларына, палатка тибындагы лагерьларга, шул исәптән Кара диңгез ярына җибәрелә. Гаризалар профильле сменаларны оештыручылар (Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасы муниципаль район (шәһәр округы) башкарма комитеты) (алга таба - профильле сменаларны оештыручылар) адресына бирелә. Профильле сменада катнашучы булган профилактик исәптә торучы балалар шәһәр читендәге ял лагерьларына һәм палатка тибындагы лагерьларга Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башкарма комитетларының вәкаләтле органнарының профильле сменаларны оештыручылар адресына заявкасы нигезендә җибәрелә.

10.3. Ата-аналардан гариза профильле сменаларны оештыручылар билгеләгән форма буенча бирелә, алар шәһәр читендәге лагерьларга, палатка тибындагы лагерьларга җибәрелә торган профильле сменада катнашучыларның җыелма исемлеген төзи.

10.4. Профильле сменада катнашучыларның һәрберсе өчен җыелма исемлектә түбәндәгеләр күрсәтелә:

профильле сменада катнашучының фамилиясе, исеме, атасының исеме;

ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) фамилиясе, исеме, атасының исеме (балигъ булмаган гражданнар өчен);

профильле сменада катнашучының туган көне, җенесе;

туган урыны һәм теркәлү урыны;

профильле сменада катнашучы йөргән балаларга өстәмә белем бирү оешмасының, иҗтимагый оешманың мөрәҗәгате яки профильле сменада катнашучының казанышлары исемлеге (гариза бирү датасыннан алдагы биш ел эчендә икедән бишкә кадәр (дипломнар, грамоталар һ.б.)).

10.5. Профильле сменаны оештыручы профильле сменада катнашучыларның җыелма исемлеге нигезендә шәһәр читендәге лагерьларның, палатка тибындагы лагерьларның профильле сменаларында аларның ялын оештыру планын формалаштыра.

10.6. Профильле сменада катнашучы балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру планында түбәндәгеләр була:

дәүләт (муниципаль) йөкләмәсе нигезендә профильле сменаларда катнашучылар җибәрелә торган дәүләт (муниципаль) шәһәр читендәге (туристлык) лагерьлар исемнәре, урыннар һәм сменалар саны;

шәһәр читендәге лагерьларга закон нигезендә үткәрелә торган ачык конкурс нәтиҗәләре буенча сатып алына торган юлламалар саны.

10.7. Профильле сменаларда катнашучы балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру планы балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру мәсьәләсе буенча профиль сменаларын оештыручы регламенты нигезендә профильле сменаларны оештыручының оештыру документы белән раслана. Балаларның һәм яшьләрнең профильле сменаларда, шул исәптән палатка тибындагы лагерьларда булулары Россия Федерациясе законнары һәм балаларның ата-аналары (законлы вәкилләре) яисә балигъ булган катнашучының үзе белән төзелгән шартнамә белән җайга салына. Урнаштыру, төзү, карап тоту һәм эшне оештыру шартлары санитария-эпидемиология кагыйдәләренә һәм гигиена нормативларына, янгынга каршы һәм террорчылыкка каршы куркынычсызлык таләпләренә туры килергә тиеш.

10.8. Профильле сменалар башланганнан соң өч көн эчендә профильле сменаларны оештыручылар Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы адресына ял оешмаларына кергәннәр саны турында мәгълүмат җибәрә.

10.9. Ай саен профильле сменаларны оештыручылар, ял иткән балаларның санын һәм аларның ялын оештыруга бүлеп бирелгән акчаларның күләмен күрсәтеп, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы адресына ял оештыру турында мәгълүмат җибәрә.

## 11. Палатка тибындагы лагерьда балаларның һәм яшьләрнең ялын һәм сәламәтләндерүне оештыру тәртибе

11.1. Палатка тибындагы лагерьда катнашу өчен республика, бөтенроссия, халыкара конкурсларда, ярышларда һәм олимпиадаларда җиңүчеләр һәм призерлар, иҗади сәләтле балалар, волонтерлар, балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре активы әгъзалары, мәгариф оешмаларында укучылар, опекун һәм тәрбиягә бала алган гаиләләрдә тәрбияләнүче ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар оешмаларында тәрбияләнүчеләр, авыр тормыш хәлендә булган балалар, махсус хәрби операциядә катнашучыларның балалары, балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләрендә тәрбияләнүче балалар җибәрелә.

11.2. Катнашучылар палатка тибындагы лагерьга балигъ булу яшенә җитмәгән катнашучы өчен ата-аналарның (яки законлы вәкилләрнең) гаризасы нигезендә җибәрелә.

11.3. Ата-аналарның гаризасы шәһәр яны лагерьларына җибәрелә торган профильле сменада катнашучы балаларның җыелма исемлеген формалаштыручы «Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ тарафыннан билгеләнгән форма буенча бирелә.

11.4. Җыелма исемлектә профильле сменаның һәр катнашучысы өчен түбәндәгеләр күрсәтелә:

баланың исеме, фамилиясе, атасының исеме;

ата-аналарның (яки законлы вәкилләрнең) фамилиясе, исеме, атасының исеме; ата-аналарның (яки законлы вәкилләрнең) эш урыны; баланың туган елы, ае, көне, җенесе;

бала укый торган мәгариф оешмасының исеме; сменада катнашучы йөри торган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмасының, иҗтимагый яшьләр оешмасының исеме (булган очракта);

баланың казанышлары яки иҗтимагый оешмалар яки берләшмәләр тәкъдимнәре исемлеге; бала укый торган сыйныф.

11.5. «Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ профильле сменаларда катнашучы балаларның җыелма исемлеге нигезендә палатка тибындагы лагерьда ял итү планын формалаштыра.

11.6. Профильле сменаларда катнашучы балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру планыбалаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру мәсьәләсе буенча профильле сменаларны оештыру регламенты нигезендә профильле сменаларны оештыручының күрсәтмә документы белән раслана.

11.7. Профильле сменалар башланганнан соң өч көн эчендә профильле сменаларны оештыручылар Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына ял итү оешмаларына килгән кешеләр саны турында мәгълүмат җибәрә.

11.8. Ай саен, 25 числога кадәр, профильле сменаларны оештыручылар Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы адресына, ял иткән балалар санын һәм балаларның ялын оештыруга бүлеп бирелгән акчаларны күрсәтеп, ял итүне оештыру буенча мониторинг җибәрә.

## 12. Опекунлык һәм тәрбиягә бала алучы гаиләләрдә тәрбияләнүче ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар һәм ятим балалар өчен оешмаларда тәрбияләнүчеләрнең ялын оештыру тәртибе

12.1. Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар оешмаларында тәрбияләнүчеләр, опекунлык һәм тәрбиягә бала алган гаиләләрдә тәрбияләнүче ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар оешмалары җитәкчеләренең Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына биргән гаризалары нигезендә шәһәр читендәге ял лагерьларына җибәрелә.

12.2. Оешма җитәкчеләренең (яисә законлы вәкилләренең) гаризалары

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан расланган формада әлеге оешма өчен Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы җиткергән хезмәт күрсәтүләрнең иң чик күләменнән артмаган күләмдә бирелә.

12.3. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы гаризалар нигезендә шәһәр яны ял лагерьларына җибәрелә торган балаларның җыелма исемлеген төзи.

12.4. Җыелма исемлектә күрсәтелә:

баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме;

гариза биргән ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, опекун һәм тәрбиягә бала алган гаиләләрдә тәрбияләнүче ятим балалар (яисә законлы вәкилләр) өчен булган оешма җитәкчеләренең фамилиясе, исеме, атасының исеме;

датасы, ае, туган елы, баланың җенесе;

«Ял оештыру турында»Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 29 апрелендәге 346 номерлы карары, бала укый торган белем бирү оешмасының исеме; бала укый торган сыйныф.

12.5. Ятим балаларның, ятим калган балаларның ялын оештыру һәм аларны савыктыруны оештыру планында

опекун һәм тәрбиягә бала алган гаиләләрдә тәрбияләнүче ата-аналар һәм ятим балалар тәрбиясендә шәһәр яны ял лагерьларына юлламалар саны, шул исәптән закон нигезендә үткәрелә торган конкурс процедуралары йомгаклары буенча сатып алынучы юлламалар саны күрсәтелергә тиеш.

12.6. Ятим балаларның, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның һәм опекун һәм тәрбиягә бала алган гаиләләрдә тәрбияләнүче ятим балаларның ялын һәм сәламәтләндерүен оештыру планы Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы белән раслана.

## 13. Санатор-курорт оешмаларында балаларның һәм яшьләрнең ялын һәм сәламәтләнүен оештыру тәртибе

13.1. Шифаханә-курорт оешмаларында сменалар оештыру тәртибе Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан билгеләнә.

13.2. Шифаханә-курорт оешмаларында сменалар оештырганда, медицина оешмалары күрсәтмәләре һәм (яки) Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Балтач муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге биргән мәгълүмат буенча, хроник авырулары булган һәм тернәкләндергеч дәвалауга мохтаҗ булган 4 яшьтән алып балаларның һәм 35 яшькә кадәрге яшьләрнең, шул исәптән авыр тормыш хәлендә булган балаларны да кертеп, ата-аналарының (яки законлы вәкилләренең) берсе белән бергә һәм инвалид балалар, үз-үзләренә хезмәт күрсәтергә сәләтле, озата йөрүчесез, ял оешмасына юллама бирү

өлешендә Социаль хезмәт алудан баш тартмаган, шулай ук иҗади сәләтле һәм социаль актив, торгызу дәвалавына мохтаҗ балаларның ялын һәм савыктыруны оештыру рөхсәт ителә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2024 елның «20» 11
272 номерлы карарына
3 нче кушымта

**Балтач муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен һәм эш белән тәэмин ителүен оештыру буенча ведомствоара комиссия турында НИГЕЗЛӘМӘ**

1. Балтач муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен һәм эш белән тәэмин ителүен оештыру буенча район комиссиясе (алга таба – Комиссия) балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру максатыннан төзелде һәм Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының координация органы булып тора (алга таба-башкарма комитет).

2. Комиссия үз эшчәнлегендә гамәлдәге федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына һәм әлеге Нигезләмәгә таяна.

3. Комиссиянең төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

министрлыклар, төрле фондлар, акционер җәмгыятьләр, барлык милек рәвешләрендәге предприятиеләр һәм берләшмәләр, балаларның һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен һәм эш белән тәэмин ителүен оештыру һәм әзерләү буенча иҗтимагый оешмалар эшчәнлеген координацияләү;

балаларның һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен һәм эш белән тәэмин ителүен оештыру буенча ведомстволар, оешмалар, учреждениеләр һәм предприятиеләр эшчәнлегенә анализ, комиссия утырышларында аларның эшчәнлеге турында мәгълүматны тыңлау, үз вәкаләтләре чикләрендә тәкъдимнәр һәм карарлар кабул итү, аларның үтәлешен тикшерү;

балаларның һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен һәм эш белән тәэмин ителүен оештыру һәм финанслау мәсьәләләрен карау;

Балтач муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялы, сәламәтләндерүе һәм эш белән тәэмин ителүе программасын гамәлгә ашыруны контрольдә тоту (алга таба - Программа).

4. Комиссия түбәндәгеләргә хокуклы:

балаларның һәм яшьләрнең ялы, сәламәтләндерүе һәм эш белән тәэмин ителүе программаларын расларга;

балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр эшләү һәм аларны башкарма комитетка кертү;

балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыруда катнашучы ведомстволардан, предприятиеләрдән, учреждениеләрдән аның компетенциясенә караган документларны, белешмәләрне, материалларны соратып алырга;

балаларның һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен һәм эш белән тәэмин ителүен оештыру мәсьәләләре буенча башкарма комитет карарлары үтәлешен контрольдә тотарга;

башкарма комитетка Программага үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында тәкъдимнәр кертергә.

5. Комиссия «Лето» балаларның һәм яшүсмерләрнең сәламәтләндерүен, ялын һәм эш белән тәэмин ителүен оештыру буенча республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә ай саен 25 числога кадәр программаны гамәлгә ашыруга бүлеп бирелгән акчалардан арту нәтиҗәсе белән, файдалану турында хисап тапшыра.

6. Балаларның һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен һәм эш белән тәэмин ителүен оештыру мәсьәләләре буенча кабул ителгән комиссия карарлары барлык ведомстволар, предприятиеләр, учреждениеләр тарафыннан үз компетенцияләре чикләрендә үтәлергә тиеш.

7. Комиссияне рәис җитәкли. Комиссия составына кызыксынучы ведомстволар һәм оешмалар вәкилләре керә.

Комиссия рәисе аның эшчәнлеге белән җитәкчелек итә, Комиссия утырышларын алып бара, Комиссиянең эш планын раслый. Комиссия рәисе булмаганда аның вәкаләтләрен Комиссия рәисе урынбасары башкара.

8. Комиссия составына шулай ук Комиссия секретаре да керә. Комиссия секретаре Комиссия утырышларын әзерләү эшен оештыруны һәм Комиссия утырышларында кабул ителә торган карарларның үтәлешен мониторинглауны гамәлгә ашыра. Комиссия эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре буенча секретарь комиссия рәисе һәм аның урынбасары йөкләмәләрен үти.

9. Комиссия үз эшчәнлеген утырышларда кабул ителә һәм комиссия рәисе тарафыннан раслана торган эш планнары нигезендә башкара.

10. Комиссия утырышлары кирәк булган саен, әмма кварталга кимендә бер тапкыр үткәрелә. Утырышның көн тәртибен һәм аларны уздыру тәртибен Комиссия рәисе билгели.

11. Әгәр утырышта Комиссия әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, Комиссия утырышы тулы хокуклы дип санала.

12. Комиссия карарлары утырышта катнашучы затларның гади күпчелек тавышы белән кабул ителә, Комиссия рәисе кул куйган һәм үтәү өчен мәҗбүри булып торган утырыш беркетмәләре белән рәсмиләштерелә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2024 елның «20» 11
272 номерлы карарына
4 нче кушымта

**2024 елга Балтач муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялын,сәламәтләндерүне, мәшгульлеген оештыру буенча ведомствоара комиссия**
**СОСТАВЫ**

| | |
|---|---|
| Гайнетдинов И. Ф. | Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, комиссия рәисе; |
| Мөхәрләмов Р.К. | «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты Мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы, комиссия рәисе урынбасары; |
| Рамазанов Ф.З. | «Балтач район башкарма комитеты Мәгариф идарәсе» МКУ методисты, комиссия секретаре (килешү буенча). |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Сибгатуллин А.З. | «Балтач районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ директоры (килешү буенча); |
| Яппаров Н.Г. | Россия Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм бәла-каза нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсенең күзәтчелек эшчәнлеге идарәсенең Балтач һәм Кукмара муниципаль районнары буенча күзәтчелек эшчәнлеге бүлегенең өлкән инспекторы (килешү буенча); |
| Гатиятуллина А. Ф. | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Балтач муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| Заһидуллин Р. Р. | Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге башлыгы; |
| Усманов И. К. | Россия Эчке эшләр министрлыгының Балтач районы буенча бүлегенең полиция начальнигы - комиссия әгъзасы (килешү буенча); |
| Петров И.И. | Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының мәдәният бүлеге башлыгы; |
| Дәүлиев Г. Д. | «Балтач район үзәк хастаханәсе» ДАССУнең баш табибы (килешү буенча). |
| Тәкиева Ә. И. | ДЛОЛ МБУ «Романтик» җитәкчесе |
| | Кулланучылар хокукларын яклау һәм кешенең уңай тормышы өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Биектау, Арча, Әтнә, Балтач районнарында территориаль бүлегенең белгеч-эксперты |

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2024 елның «20» 11
212 номерлы карарына
5 нче кушымта

**Балтач муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ял һәм сәламәтләндерү оешмаларын әзерләп бетерү һәм аларны комплекслы тикшерү буенча эшче төркем СОСТАВЫ**

| | |
|---|---|
| Гайнетдинов И. Ф. | Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, комиссия рәисе; |
| Мөхәрләмов Р.К. | «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты Мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы, комиссия рәисе урынбасары; |
| Яппаров Н.Г. | Россия Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм бәла-каза нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсенең күзәтчелек эшчәнлеге идарәсенең Балтач һәм Кукмара муниципаль районнары буенча күзәтчелек эшчәнлеге бүлегенең өлкән инспекторы (килешү буенча); |
| Заһидуллин Р. Р. | Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге башлыгы; |
| Ганиев Р.Р. | «Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләрен ведомстводан тыш сакның Татарстан Республикасы буенча идарәсе» федераль дәүләт казна учреждениесенең Балтач районы буенча ведомстводан тыш сак бүлеге (килешү буенча); |
| Дәүлиев Г. Д. | «Балтач район үзәк хастаханәсе» ДАССУнең баш табибы (килешү буенча); |
| Хәсәнов Р.Т. | «Татарстан Республикасы буенча Гигиена һәм Эпидемиология үзәге» федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесе (килешү буенча); |
| Тәкиева Ә. И. | ДЛОЛ МБУ «Романтик» җитәкчесе |
| | Кулланучылар хокукларын яклау һәм кешенең уңай тормышы өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Биектау, Арча, Әтнә, Балтач районнарында территориаль бүлегенең белгеч-эксперты (килешү буенча); |